РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423646 Республика Татарстан, Менделеевский район, д.Псеево
ул. Центральная, д.4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

423646 Татарстан Республикасы, Менделеевск районы,
Песәй авылы, Үзәк урам,4 йорт

Тел. (факс): (85549) 3-71-22 e-mail: Psv.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**25 нче ноябрь 2022 ел** **№ 5**

Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены үткәрү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131 нче номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 ст., 2004 елның 28 июлендәге 45 нче номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын 2022 нче елның 8 нче декабренә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә . Җыенны үткәрү урыны итеп Тукай авылы, Урман урамы, 15 нче йортны билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
   «Сез 2023 елда Менделеевск муниципаль районы Тукай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме? I һәм II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылар, тәрбиясендә балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләр һәм көндезге (көндезге) уку формасы студентлары өчен , Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнарга бер тапкыр түләүне киметергә һәм 500 сум күләмендә акча билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларына түләүдән азат итәргә, һәм әлеге категория гражданнар өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
   1.юлларны кардан чистартырга

“Риза” “каршы”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында: http://mendelevsk.tatarstan.ru Песәй авыл җирлеге бүлегендә бастырып чыгарырга
4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Песәй авыл җирлеге башлыгы В. И. Мөхәммәтгалиев